
Туган тел конена һәм Габдулла Тукайнын 140 еллыгына багышлап 24 - 26 апрельдә татар телендә сөйләvчеләр, өйрәнvчеләр һәм яратучылар очен унберенче тапкыр «Татарча диктант» акциясе Россиянен кvп кенә тобәкләрендә, хәтта чит илләрдә дә vтте. Мордовиянен торле почмакларында яшәгән татарлар акциягә кушылып диктантларны яздык. 

Ә беренчеләр рәтендә «Татарча диктант» акциясендә Казанда vткән Ботендонья «Туган тел» форумында катнашкан Мордовия делегатлары язды.
Чаранын топ максаты – татар телен саклау һәм аны кин җәмәгатьчелек арасында популярлаштыру, грамоталылык дәрәҗәсен кvтәрv, татар телен өйрәнvгә кызыксыну уяту, шулай ук татар халкынын милли vзанын һәм мәдәни vзенчәлеген ныгыту.
Беренче елларда акция Татарстан-да һәм берничә тобәктә генә vткәрелсә, сонгы елларда ул кин гео-графиягә ия зур проектка әверелде. Бvгенге кондә акция 26 илдә һәм Россия Федерациясенен 73 тобәгендә яшәvче милләттәшләребез катнашында узды.
Елдан-ел катнашучылар саны арта: акция мәйданчыкларында һәм онлайн форматта менләгән кеше vзенен татар телен белv дәрәҗәсен сынап карый.

Диктант оч дәрәҗәдә vткәрелде: татар телен башлангыч дәрәҗәдә белvчеләр очен; татар телен урта дәрәҗәдә белvчеләр очен; татар телен камил дәрәҗәдә белvчеләр очен. Әлеге структура һәр катнашучыга vзенә туры килгән дәрәҗәдә сынау vтәргә мөмкинлек бирә.
Акция вакыты һәм форматы безгә билгеле. «Татарча диктант» ике форматта оештырыла: офлайн – махсус мәйданчыкларда (мәктәпләр, университетлар, мәдәният vзәкләре, китапханәләр һ.б.); онлайн – рәсми сайт аша (https://diktant.tatar).
Ел саен «ТНВ-Татарстан» һәм «ТНВ-Планета» телеканалларында трансляция вакытында татарча диктант язып киләбез. Мин ел саен «ТНВ-Планета» каналында трансляцияләнгән татар телен урта дәрәҗәдә һәм татар телен камил дәрәҗәдә белvчеләр очен текстларны язып карыйм. Быел Габдулла Тукайнын «Туган тел» шигыре белән «Бәхет»еннән, «Исемдә калганнар»дан озекләрне яздым. Укытучым филология фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе атказанган мәдәният һәм Татарстан Рес-публикасы атказанган фән эшлеклесе Фоат Галимулла улы Галимуллин укыган диктантны язу vзе бер бәхет: зур рәхмәт сезгә, кадерле укытучым Фоат абый!

«Исемдә калганнар»дан озекне Россия һәм Татарстан халык артисты Венера Әхәт кызы Ганиева укыды. Шулай ук чит илләрдә яшәгән туганнарыбызга югары профессиональлек белән Татарстан Республикасы атказанган энергетигы, кызыклы тапшырулар алып баручы Хәбри Хәбриев (Данияр Галимулла улы Хәбриев) укыган диктантны да язып карадым. Мина бик тә ошады.



2026 елнын 24 апрелендә Мордовия М.Е.Евсеев исемендәге педагогия университетында Габдулла Тукайнын 140 еллыгына багышланган «Татарча диктант – 2026» Ботендонья акциясе узды. Катнашучылар - вуз студентлары һәм укытучылары булды - гомуми саны 50 кешедән артып китте. Диктант башланыр алдыннан студентлар Габдулла Тукайнын биографиясен һәм ижатын белv буенча ижади бәйгедә катнаштылар.
Шул ук конне Саранск шәһәре «Ру-хи-мәдәни vзәк» бинасында «Татарча диктант»ны яздылар. Барысы турында Үзәкнен педагог-психологы Динара Наиль кызы Шабаева сойләде: «Диктантны Ләмберә районы Аксён урта мәктәбе укытучысы, «Ин яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Ботенроссия конкурсы призеры Айлина Юнир кызы Абузярова яздырды. Барлыгы 25 кеше язды: «Рухи-мәдәни vзәк» яшьләре активы, биредә гарәп теле һәм Корьән ойрәнергә йоргән группа вәкилләре, «Бәлеш» милли-мәдәни проектында катнашучылар.
Темага килгәндә, чара Габдулла Тукаебызга багышланганга, диктант ике олештән торды; башта- «Туган тел»не язган булсак, аннары - «Исемдә калганнар»дан озек иде. Диктанттан сон Перьмнын «Шvрәле остәл уеннары клубы» («Клуб настольных игр Шурале») житәкчесе Руслан Галимов Габдулла Тукай ижатына багынлап ясалган интеллектуаль остәл уеннары уйнатты.»
Ләмберәнен беренче, икенче урта мәктәпләре, Чирмеш топ гомуми белем бирv мәктәбе укучылары, укытучылары, районнын «Алмаз» мәдәни-спорт vзәге хезмәткәрләре, «Ләмберә яшьләре» жәмгыятчелеге вәкилләре белән берлектә, тәжрибәле педагог Фазия Фәрит кызы Боярова укыган диктантны оч дистәгә якын кеше язган. Аннары дvрт группага бvленеп, Габдулла Тукай биографиясен белv буенча викторинада да катнашканнар. Тагы әлеге район халкынын теләгәннәре онлайн форматта да язып караучылар байтак булды.
Диктант язу турында Фазия Фәрит кызы болай ди: «Бvген Габдулла Тукаебызнын 140-еллыгына багышланган «Татарча диктант» татарларны һәм татар теле, мәдәнияте һәм әдәбияты белән кызыксынучыларны, яшәv урынына карамастан, берләштерvче әһәмиятле халыкара проектларнын берсе булып тора. Акциянен топ максаты - дорес язуны ойрәнv һәм камилләштерv, әдәби татар телен белvне ныгыту, шулай ук татар халкынын бай мәдәни мирасына катнашу хисен vстерv, ботен донья буйлап татарларны берләштерv.
Яшьләр актив рәвештә акциягә кушылды, туган телгә булган мә-хәббәтләрен һәм белемнәрен кvр-сәттеләр. Катнашучыларнын һәр-берсенә рәхмәт! Сез - булдырасыз! »
Ел саен «Татарча диктант»ны Ләмберә районы Кривозерье урта мәктәбендә татар телен һәм татар әдәбияты предмтлары буенча тирән белем биргән Луиза Низаметдин кызы Смакаева житәкчелегендә яздылар. Быел да 24се конне ботендонья белем бирv акциясенә кушылдылар.
«Татарча диктант»ны Рузаевка районы Татар Пешлә мәктәбендә дә яздылар. Мәктәп сайтында болай дип язылган: «...һәркемнен йорәгендә туган теле янгырый: һәркем

vзенчә Габдулла Тукай истәлеген хормәтләде.Татар Пешлә урта мәктәбебездә татар телен яратучы һәм мәдәниятен хормәт итvчеләрне берләштергән vзенчәлекле вакыйга булды. Без боек шагыйрь Габдулла Тукайга багышланган акциягә кушылдык. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сания Спартак кызы Саляева тарафыннан боек татар шагыйре Габдулла Тукайнын 140 еллыгына багышланган «Татарча диктант» оештырылды һәм vткәрелде. Бу грамоталылык буенча кvнегv генә тvгел, ә хәтер һәм хормәт дәресе иде. Шагыйрь әсәрләренен юллары укучылар һәм педагоглар кулы астында жанланды. Алар туган якка мәхәббәт белән тулы текстны тырышып яздылар. Диктант кебек моһим һәм кирәкле формат аша шагыйрьнен vлемсез мирасына кагылу момкинлеге очен Сания Спартак кызы Саляевага рәхмәтебезне белдерәбез.
Ана телендә дорес язу - ата-бабаларынны хормәт итv дигән cvз!»

**Наилә НАСЫРОВА**